Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Глава Брюшлинского сельского поселения

Татарстан Республикасы
Менделевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
2022 елның 26 ноябреннән

КАРАР
№1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Бөрешле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге башлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 8 декабре 17 сәгатьтә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы инвалидлардан, балигъ булмаган балаларын тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән һәм көндезге укуда булган студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләреннән тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә Сез ризамы:

1) янгын гидрантларын сатып алу;
2) янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру өчен бетон боҗралар һәм люклар сатып алу;
3) боҗралар һәм янгын гидрантлары урнаштыру өчен монтаж эшләре;
4) янгын сүндерү машинасына янгын сүндерү җиңе сатып алу;
5) Бөрешле авылындагы юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
6) җәйге чорда Бөрешле авылы территориясен чабу (триммер өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
7) урам яктырткычлары сатып алу;
8) Яшьләр урамы буенча агачларны кисү;
9) спорт тренажерын сатып алу, урнаштыру

«ӘЙЕ» "ЮК".

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru “Бөрешле авыл җирлеге” булегендә урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга - http://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А.Смирнова